Бүгенге санда:

**ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫ УҢАЕННАН ЧАРАЛАР ДӘВАМ ИТӘ. 3 бит**

# Дуслык
Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 11 март 2015 ел

№ 17 (10546)

**12 мартка һава торышы:** болытлы һава, урыны белән кар ихтимал, җил көньяк- көнбатыштан 3-4 м/с; температура көндез +1°С, төнлә -5°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### АВЫЛ ЭШМӘКӘРЛӘРЕ ҖЫЕНГА БАРАЧАК

“Россиянең татар авыллары” Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының 20-22 мартта Казанда үткәрә торган татар авыллары эшмәкәрләренең 4нче Бөтенроссия җыенында безнең районнан Илсур Галиев һәм Ришат Сатдаров катнашачак.

### ШӘҺӘРДӘ ӨЙРӘНҮЛӘР ҮТӘ

Бүген шәһәрдә тактик-махсус өйрәнүләр элементлары белән команда-штаб тренировкалары үтә. Чаралар барышында “җинаятьчеләр” башкарма хакимият органнары объектларында һәм халык күпләп йөри торган урыннарда төрле вакыйгаларны имитацияләячәк. Нурлатта укулар ТР эчке эшләр министры урынбасары Дамир Динниулов җитәкчелегендә үтә.

### ПРОЕКТ ТОРМЫШКА АШЫРЫЛА

Бу көннәрдә Нурлат халкының мәшгульлеге үзәге “Яшьләр арасында хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган эшче һөнәрләр һәм инженер белгечлекләр буенча һөнәри ориентлашу чаралары үткәрү” проектын тормышка ашыру өстендә эшли. Үзәк белгечләре ел дәвамында әлеге проект кысаларында шәһәрнең балалар бакчалары, мәгариф учреждениеләрендә төрледән-төрле чаралар үткәрергә планлаштыралар.

### КЫЗЛАР ОСТАЛЫКТА ЯРЫШТЫ

Колбай Мораса авыл мәдәният йортында үткән “Ягез әле, кызлар!” конкурсында югары уку йорты тәмамлап эшләүчеләр һәм мәктәп укучылары көч сынашты. Бәйге тигез очколар белән тәмамланды. “Безнең кызлар барысын да булдыра икән!” – дип тел шартлаттылар тамаша кылып утыручы авылдашлары.

## Сугышлар гына булмасын, *дип тели ветераннар*


Автор фотосы

НУРЛАТНЫҢ МАКТАУЛЫ ГРАЖДАНИНЫ ИСЛАМ БӘХТИЯРОВ ТА ЛАЕКЛЫ БҮЛӘГЕН АЛДЫ

**Нурлатта бу эш атнасы Бөек Җиңүнең 70 еллыгы хөрмәтенә юбилей медальләре тапшыру тантаналары белән башланып китте. Сишәмбе көнне әлеге лаеклы бүләкләрен 300ләп ветеран, сугышта катнашканнарның толлары һәм тыл хезмәтчәннәре алды.**

Бу көнне Мәдәният сараенда узган тантанага Николай Кудряшов та парад кителен киеп, орден-медальләрен тагып, гаиләсе белән килгән. Ул 17 яшендә үз теләге белән сугышка китә, ике тапкыр яралана. Ветеранның күкрәген бизәп торучы бүләкләр әлеге дәһшәтле елларның кайтавазы сыман. Әмма Җиңүнең 70 еллыгы хөрмәтенә чыгарылган медальне тапшырыр алдыннан да иң беренче сугышчан бүләгемне алгандагы сыман каушыйм, ди Николай Андреевич. Башка сугыш ветераннары, толлар һәм тыл хезмәтчәннәре кебек үк ул да район башлыгы Равил Кузюров кулыннан юбилей медален рәхмәт хисләре белән кабул итте.

– Бары тик сугышны кичкән, аның михнәтләрен күргән кешеләр генә мондый афәтнең беркайчан да кабатланмавын телиләр, – дип билгеләп үтте Ольга Михайлова чамадан тыш дулкынланып. Әмма аңа, 12 яшеннән сугыш михнәтләрен кичкән ханымга күз яшьләреннән оялып тору кирәкме икән?.. Ул өлкәннәр белән беррәттән тимер юл станциясе каршындагы ярдәмче хуҗалыкта хезмәт куйган, яшелчә үстергән, уңыш җыюда катнашкан, мәктәпне ягарга булышкан, күмер ташыган, транспорт полотнасын кардан чистарткан. Ә сугыштан соң, язмышын педагогикага багышлаган, 29 ел буе башлангыч сыйныфларда укыткан. Әмма сугышның иң салкын чоры, туңган куллары белән кар астыннан бәрәңге уңышын чүпләгән вакытлары бүген дә аның хәтереннән чыкмый.

Ветераннар район башлыгы Равил Кузюровның, ТР Дәүләт Советы депутаты Рәис Сөләймановның котлау-теләкләрен дә бик җылы кабул иттеләр. Ә сәхнәдән яңгыраган сугыш турындагы шигырьләр һәм җырлар аларны 70 ел элек булган вакыйгаларга алып кайтты, ахрысы. Күңелләрне янә хәвефле хатирәләр биләп алды. Сөялле кулларында бүләкләрен кысып тоткан ветераннар, барысы да бары тик бер генә теләктә иде – сугышлар беркайчан да булмасын, дип кабатладылар алар! Юбилей медальләре тапшыруга багышланган тантана бу көнне район мәдәният йортында да үтте.

**Маргарита ЛИТТА**

АКТУАЛЬ

## Штраф автостоянкага “юллама” булырмы?

**Машина сатып алганда, авомобиль хуҗалары өстәмә комплектациягә акчаларын кызганмыйлар. Гараж яки түләүле стоянкада экономияләргә була, дип саныйлар, күрәсең. Нәтиҗәдә – күпкатлы йортларның ишегаллары парковка урыннарына әверелә.**

Бу очракта автохуҗаларны гына гаепләве кыен. Сәбәпләр төрле булырга мөмкин – өйгә якындарак гараж салу яки сатып алу мөмкинлеге юк, түләүле стоянка ерак. Аннан, машинаң, кем әйтмешли, кул астында гына булганда, җайлырак та: подъездыңнан чыгып утырдың да китеп бардың. Әмма бу очракта үзеңнең җаеңны һәм теләгеңне генә уйлыйсың, күршеләрдә гамең дә булмый. Әнә шуңа күрә күпфатирлы йортларда яшәүчеләр төрле службаларга зарланалар да, чөнки автомобильле күршеләр белән мондый нәзберек проблеманы хәл итүе бик кыен. Моңа без үзебез дә инандык. Ни өчен машинагызны биш катлы йорт ишегалдында калдырасыз, дигән сорауга Дружба урамының 75нче йортында яшәүче Андрей болай җайлы, дип җавап бирде. Гагарин ур., 28 йорттагы машина ияләре сорауга сорау белән җаваплыдылар: “Ә ни өчен биредә көн дәвамында чын машина стоянкасы хасил була? Кемдер базарга килә, димәк, аларга машиналарын калдырырга ярый, ә шул ук йортта яшәүчеләргә рөхсәт юк килеп чыгамы?..” Бу уңайдан узган ел ишегалларына парковка урыннары ясаган йортларда яшәүчеләр бәхетле. Яшьлек мкр.дагы Совет ур., 185нче йорт та шундыйлар исәбеннән. Бу йортта яшәүче Алексей парковка проблемасы хәзер бетте, дип саный: “Хәзер безнең машиналар куяр урыныбыз да, балалар мәйданчыгы, ял итү өчен эскәмияләребез дә бар. Элек күршеләр бик зарлана иде, чөнки машиналар күп бит”, – ди ул. Бу микрорайонда ишегалларын төзекләндерү барышында 6 парковка төзелгән, быел тагы 3не ясау планлаштырыла.

*(Ахыры 2нче биттә).*

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

БӘЙРӘМ МИЗГЕЛЛӘРЕ

## Барысы да гүзәл затларыбыз өчен

**7 мартта шәһәр Мәдәният сараенда Халыкара хатын-кызлар көненә багышлап узган чарада “Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз күзлегеннән” конкурсына нәтиҗәләр ясадылар.**

“Хатын-кыз – әни”, “Минем һөнәрем-минем язмышым”, “Хатын-кыз – бизнес-леди”, “Хатын-кыз – ел үрнәге”, “Хатын-кыз – мәдәният һәм рухилык”, “Ир-ат – игелекле йөрәк”, “Ир-ат – лидер” номинацияләрендә җиңүчеләрне котладылар. Шунда ук районның 10 хатын-кыз-тыл хезмәтчәне Җиңүнең 70 еллыгына багышланган юбилей медальләренә дә ия булды. Бүләкләрне өлкәннәргә район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин тапшырды. Ул район башлыгы Равил Кузюров исеменнән барлык әниләрне, гүзәл затларны язның иң матур бәйрәме белән котлады, һәрбарчасына рәхмәт һәм ихтирам сүзләре белдерде. РФ Дәүләт Думасы депутаты Фатих Сибагатуллин һәм район оешма-предприятиеләре җитәкчеләренең дә котлаулары хатын-кызларга юлланды.




ӨЛКӘН ЯШЬТӘГЕ ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ӘСХӘТ ГАБДУЛЛИН КОТЛАДЫ

Традиция буенча, чара гүзәл затларның иңнәренә ак яулыклар салудан башланды. Балалар иҗаты үзәге, үзәк китапханә, Кама аръягы һәм Нурлат тарихы төбәк музее һәм “Дива” модалар театры әзерләгән күргәзмәләр, мул чәй табыны, чәчәкләр һәм чын күңелдән әйтелгән котлау сүзләре, бәйрәм концерты – барысы да гүзәл затларга багышланды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ЭШЛЕКЛЕ СИШӘМБЕ

## Көн тәртибенә ташу темасы чыга

**Кичә гомумшәһәр планеркасын район башлыгы Равил Кузюров районда штаб өйрәнүләрен төгәл үткәрүдә катнашкан һәркемгә рәхмәт сүзләреннән башлады.** Аннан Равил Әфраимович райондагы кадрлар үзгәрешләре белән таныштырды. Нурлат районы советы аппараты җитәкчесе итеп моңарчы Биляр Озеро авыл җирлеге башлыгы булып эшләгән Олег Микушкин, башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш бүлеге җитәкчесе итеп әлегәчә “Энергострой” җәмгыятен җитәкләгән Наил Фазлыев, социаль мәсьәләләр буенча урынбасары итеп моңарчы мәдәниятне үстерү үзәге начальнигы булган Әлфия Галәветдинова билгеләнде. “Нурлатнефтепродукт” җәмгыятен Ленар Шарапов, “Нурлат урманчылыгы”н Рөстәм Галиев, җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасын Рәмис Шәйхетдинов, Нурлат балалар сәнгать мәктәбен Валентина Тяжова, контроль-хисап палатасын Марина Ибраһимова җитәкләячәк.

Иртәнге сөйләшү көн тәртибенә куелган ташуга каршы әзерлек темасын 125нче янгын часте начальнигы Илһам Курамшин яктыртты. Бездә су басу куркынычы янаган 7 авыл бар, 23 гидротехник корылма исәпләнә. Оратор район башкарма комитеты җитәкчесенең 17 февральдәге ташуга каршы тору буенча карарында күрсәтелгән пунктлар буенча эшләр алып барылуын хәбәр итте. Равил Әфраимович авыл җирлекләре башлыкларына һәр көнне хәлгә мониторинг үткәрергә, норматив-хокукый актлардан башлап, гамәли чараларга кадәр әзерлекне тәэмин итәргә чакырды. Бөек Җиңүнең 70 еллыгына әзерлекнең барышы турында район социаль яклау бүлеге җитәкчесе Ирина Афанасьева чыгышын да район башлыгы йомгаклады. Хәзер 4 сугыш ветераны фатирына ремонт бара, 5 һәйкәл ремонтлана, ветераннарның нинди федераль мөмкинлекләргә ия булуын аларның якыннарына аңлатырга, бер генә ветеранны да игътибардан читтә калдырмаска чакырды.

Иртәнге сөйләшүдә санитар икеайлыкка әзерлек темасы да күтәрелде. Соңыннан бертөркем катнашучыларга төрле дәрәҗәдәге конкурсларда җиңүләре өчен Дипломнар һәм намуслы хезмәтләре өчен район башлыгының Рәхмәт хатлары тапшырылды.

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА**

## Штраф автостоянкага “юллама” булырмы?

*(Ахыры. Башы 1нче биттә).*

– Совет ур., 187нче йорт ишегалдында зур парковка төзергә исәп тотабыз, – диде ТСЖ мастеры Фәридә Гыйльметдинова, һәм моны биредә балалар бакчасы булуы белән дә бәйләде. Бу микрорайонда парковка мәсьәләсе хәл ителеп килә, әмма автостоянкаларны хәтерләтүче ишегаллары да шактый әле. Шул көннәрдә күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге начальнигы Николай Захаров шәһәрлеләрдән кергән зарлар буенча Кариев, Нурлат, Гыйматдинов һәм башка урамнардагы кайбер ишегалларын карап чыкты.

– Күпкатлы йортларда яшәүчеләр ишегалларында калдырылган машиналар аркасында хәтта бала арбасы белән дә үтмәле түгел, дип зарланалар, – диде ул. – Кар-бозны да чистартып булмый, әмма иң мөһиме, махсус машиналар, мәсәлән, “ашыгыч ярдәм”, янгын сүндерү техникасы керә алмый. Ә бит ишегалларында парковка һәм төзекләндерү кагыйдәләрендә ишегалларында, махсус урыннардан тыш, башка җирләрдә машиналарны калдыру тыелган.

Әмма газоннарда, тротуарларда, өйгә килүче юл уртасында көне-төне шәхси машиналар торуын еш күрергә була. Ә бит бу урыннарда хәтта пассажирлар утыру яисә төшерү, нәрсәдер төяү-бушату өчен тиз арада гына туктап алырга да ярамый.

– Машина хуҗалары транспортларын подъезд тирәләрендә, кешеләрнең тәрәзә каршыларында калдырганда, үз күршеләренә нинди уңайсызлык тудырулары хакында уйлап та карамыйлар, – дип сөйли Николай Захаров. – Моннан тыш, машина җылынган арада аннан чыккан төтен форточка аша беренче каттагы фатирларга үтә. Ә ишегалды, кем әйтмешли, техника белән тулган очракта ни була инде?..

Күзәтчелек эшчәнлеге начальнигының сүзләрен ТКХ ИК МУПы җитәкчесе дә тулыландыра.

– Машиналар белән тулган ишегалларында безгә дә эшләве кыен, – ди Фәнис Бакиров. – Чүп түгү машиналары контейнер-бункерларны үзвакытында алыштыра алмыйлар. Ә аннан фатирны хуҗалары үзләре үк контейнер мәйданчыклары чүп белән тулган, дип зарланалар. Асылда мондый ситуация Нурлат ур., 33, Кариев ур., 32 һәм 34нче йортларда күзәтелә, Промышленная урамының ике ягында да һәрчак машиналар тора. Без ТСЖ җитәкчеләре белән элемтәгә керәбез, күпләре безне аңлый, фатир хуҗаларын кисәтә, әмма бу хәлне аңлап бетермәүче идарәче компанияләр дә бар.

...Шәһәр юлларындагы хәрәкәтнең тыгызлыгыннан күренгәнчә, автохуҗалар саны елдан-ел арта. Шул ук вакытта шәһәр үзе дә үсә тора, яңа йортлар пәйда була. Элегрәк нормативларда парковка урыннары каралмаган булса, район башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы Наталья Крайнова әйтүенчә, хәзер, ситуация үзгәргән.

– Беренчедән, җирдән файдалану кагыйдәләре буенча, проектлаган вакытта һәр фатирга бер машина урыны исәбеннән җир бүленергә тиеш, – диде ул. – 19 мартта шәһәрнең төньяк-көнчыгыш өлешендәге планировка проектын карау буенча җәмәгать тыңлаулары булачак, анда күпбалалы гаиләләргә участоклар бирелгән. Биредә күп яруслы автостоянка салу планлаштырыла.

...Ә парковка урыннары мәсьәләсе хәл ителгән арада, ЮХИДИ һәм күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге күпфатирлы йортлардан кергән зарлар буенча эшләрен дәвам итәләр. Николай Захаров әйтүенчә, бер рейд барышында 6 беркетмә төзелгән, тагы 10сы караудa, ди. Димәк, хөрмәтле автохуҗалар, үз ишегалдыгызда фотоаппаратлы ОНД хезмәткәрләрен күрсәгез, гаҗәпләнмәгез һәм уведомление алырга да әзер торыгыз. Бәлкем, беренче штраф автостоянкага “юллама” сыман булыр...

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ХӘБӘРЛӘР

### РЕСУРС ҮЗӘГЕ БУЛАЧАК

**Сишәмбе көнне район башлыгы Равил Кузюров катнашында узган киңәшмәдә сүз Нурлат аграр техникумы каршында агросәнәгать юнәлешендә кадрлар әзерләү буенча ресурс үзәге булдыру хакында барды.**

Ресурс үзәге нигездә “АгроИнвест” идарәче компаниясенә караган предприятиеләр өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләү һәм кабаттан әзерләү белән шөгыльләнәчәк. Киңәшмәдә компаниянең генераль директоры Рәис Сөләйманов катнашып, ресурс үзәге иң беренче чиратта хезмәт базарында тәҗел булган һөнәрләр буенча көн таләпләренә җавап бирерлек белгечләр әзерләргә тиеш, ди[...] ассызыклады. Аграр техникум директоры Ирек Камалов һәм “Ресурс үзәге” проекты җитәкчесе Зилә Хисмәтова үзәкне оештыру планы белән таныштырдылар. Шунда ук район башкарма комитеты, мәгариф идарәсе, төзелеш бүлеге һәм башка тармак белгечләре катнашында оештыруга кагылышлы сораулар, мәсьәләләр хакында да сү[...] барды.

Республикада бүгенге көндә 10 ресурс үзәге эшләп килә, шуларның берсе агросәнәгать юнәлешендә кадрлар әзерли. Ресурс үзәкләре Мәгариф һәм фән министрлыгы белән эш бирүчеләрнең уртак финанславы шартларында оештырыла. Ресурс үзәге оештырылу уку йортының матди-техник базасын да ныгытырга ярдәм итәр, белем бирү процессы да уңай якка үзгәрер дип фаразлана, чөнки белгечләрне стратегик партнер – бу очракта “АгроИнвест” идарәче компаниясе белән берлектә эшләнгән махсус программалар буенча әзерләячәкләр бит. Равил Әфраимович ресурс үзәге оештыруның алда торган җитди бурыч булуын билгеләп, бер ай эчендә кирәкле документларны әзерләргә кушты, эшләрне башкару өчен төрле тармаклардан җаваплыларны билгеләде. Нурлатта үз[...] инде 2016нчы елдан эшли башлар, ди[...] күздә тотыла.

**Лилия МӨБАРӘКШИ[...]**

### ӨЙ ТУЛЫСЫНЧА ЯНГА[...]

**Шимбә көнне 2нче Дачная ур[...]мында янгын килеп чыга. Ан[...] нәтиҗәсендә, кирпеч белән тышла[...]ган 10х8 метрлы щитлы йорт тул[...]сынча янып бетә.**

Ут электр үткәргечендәге кыска я[...]ганыштан килеп чыга. Күзәтчел[...] эшчәнлеге бүлеге мәгълүматларынн[...] күренгәнчә, өйдәге бүлмәләрнең бе[...]сендә эрегән электр үткәргече кар[...]ватка төшә һәм аңа ут каба. Хуҗал[...] ярдәм сорап чыгып йөгерәләр. Ач[...] калган ишектән мул итеп кислор[...] керә, нәтиҗәдә, ут тагы да көчәя.

Бу өйдә 3 кешелек гаилә яши тор[...] була, бәхеткә, корбаннар юк.

**Сирень СӘМӘРХАНО[...]**

### РЕЙДЛАР ҮТКӘРЕЛ[...]

**2 марттан 13енә кадәр 73нче янг[...] часте сагы астындагы объектлар[...]** “Нурлатнефть” НГДУсының янгын-тех[...] комиссияләре һәм шулай ук кызыкс[...]ган службалары белән берлектә вак[...]лыча утлы эшләр үткәргәндә янгын к[...]кынычсызлыгы кагыйдәләрен истә то[...]ны тикшерү буенча рейдлар үткәрела[...]

Рейдларның максаты - вакытл[...] утлы эшләр үткәргәндә янгын куркын[...]сызлыгы нормаларын һәм кагыйдәлә[...]бозуны булдырмау.

**Галина ПИЯНЗИНА, 73нче янгын ча[...] инспект[...]**

# Медальләр ияләрен таба тора

**САН**

Районда 21 февральдән старт алган акция кысаларында 1508 кешегә "1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына" юбилей медале тапшырылачак.




КАМИЛ ЙОСЫПОВКА ЮБИЛЕЙ МЕДАЛЕ ТАПШЫРЫЛДЫ.

5 мартта Үрнәк авылында яшәүче тыл хезмәтчәне Миннеруй Нуруллина өчен икеләтә бәйрәм булды – Халыкара хатын-кызлар бәйрәме алдыннан үзенең 90 яшьлек юбилеен да билгеләп үтте ул. Юбилей көнендә аны район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова, социаль яклау идарәсе начальнигы Ирина Афанасьева, Киекле авыл җирлеге башлыгы Рәфис Ганиев һәм башкалар гомер бәйрәме белән тәбрикләделәр. Заманында Урта Чаллы авылында туган Миннеруй әби – гаиләдә беренче бала. Тормышның барлык авырлыкларын тарту насыйп булган аңа. Мәктәпнең башлангыч сыйныфын тәмамлау белән колхозга эшкә чыга. Аннан сугыш башлангач, Саратов өлкәсенә үзе сорап урман кисәргә китә. Шунда якташы, Үрнәк авылы егете Мингәрәй белән танышып, гаилә корып җибәрәләр. Сугыш тәмамланганнан соң, яшь гаилә Үрнәк авылына кайтып төпләнә. Һәм 58 ел бергә иңгә-иң куеп яши алар. Шул еллар эчендә 4 баланы, 6 оныкны тормыш юлына бастырганнар. Инде ике улларын югалту кайгысын да кичергәннәр. Әби тормышның авырлыкларын күп күрсә дә, зарланмый. Бүгенге тыныч тормышка шөкерана итеп яши.

Флюра Рәшитовна юбилярны РФ һәм ТР Президентлары Владимир Путин, Рөстәм Миннеханов һәм район башлыгы Равил Кузюров исеменнән котлап, бүләкләр тапшырды, сәламәтлек теләде. Шунда ук район башлыгы урынбасары тыл хезмәтчәненә "1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына" юбилей медален дә тапшырды.

8 март бәйрәме алдыннан Өлкәннәр һәм инвалидлар йортында яшәүче сугыш инвалиды, ветеран толы һәм 20 тыл хезмәтчәне дә юбилей медальләренә ия булдылар. Бүләкләрне өлкәннәргә район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова тапшырды. Ул өлкәннәрне Халыкара хатын-кызлар көне белән котлап, район җитәкчелегенең җылы теләкләрен җиткерде. Бу көнне РФ Президенты Владимир Путинның бүләгенә ия булган 22 кешенең һәркайсының үз язмышы. Сугыш михнәтләрен кичкән I группа инвалид, сугыш ветераны Габбас ага Батыршин инде 4 ел урын өстендә. Тыл хезмәтчәне Камил Йосыповка сугыш башланганда исә нибары 10 яшь була.

- 4 нче сыйныфны тәмамлап, колхозга эшкә чыктым, - ди Камил ага. – Шул еллар эчендә сугышта 2 абыем, авырып әнием үлде, әти сугышта иде. Без 4 бала шулай ялгыз үстек. Иң кечкенәбезгә нибары 5 яшь иде.

Юбилей медальләре тапшыру белән башланган чара "Ягез әле, әбиләр" конкурсы белән дәвам итте. Бу көнне әбиләр төрле конкурсларда, уеннарда, бәйрәм программасында катнаштылар.

**Зилия ӘКСАНОВА**




ЭЧКЕ ЭШЛӘР БҮЛЕГЕ ВЕТЕРАННАРЫ УКУЧЫЛАР БЕЛӘН.

# Мәргәннәр ярышты

**Җиңүнең 70 еллыгы кысаларында ОВД ветераннары һәм Киекле урта мәктәбе укучылары командалары арасында пневматик мылтыктан ату буенча ярышлар узды. "Форпост" яшьләр формированиесе районның ветераннар Советы белән берлектә оештырган әлеге чараны алга таба традицион итмәкче.**

– Мондый ярышлар патриотик тәрбия ягыннан да бик мөһим, - ди районның ветераннар Советы рәисе Разия Садретдинова. – Озак еллар районның эчке эшләр бүлегендә хезмәт куйган ветеран-остазлар яшьләр белән тәҗрибә уртаклаштылар. Ярышлар ике категориядә: шәхси зачетта һәм командалар арасында узды. Иң көчлеләр дип ветераннар командасы табылды. Шәхси зачетта укучылар арасында Илүзә Зәйдуллина I, Рөстәм Гыйләҗев II урынга чыктылар. Ветераннар арасында Николай Рассадин һәм Ильяс Туктаров җиңү яулады. II урын Владимир Матюшкинга бирелде.

29 ел хезмәтен район эчке эшләр бүлегенә биргән милиция подполковнигы Людмила Щекач өчен мондый ярышлар яңалык түгел. Республика ОВДлары арасында узган шундый конкурсларның берсендә призлы III урынны яулаган булган ул. Шуңа күрә дә бүгенге ярыш аның өчен кыенлык тудырмады.

**Зилия ӘКСАНОВА**

**Газетаның электрон версиясен nurlat-tat.ru сайтында укыгыз**

# Сокланырлык гомер кичерделәр



СОҢЫННАН ИСТӘЛЕККӘ ФОТОГА ТӨШТЕК

**Гомер буе бер урамда күрше булып яшәгән Сәлим ага һәм Закира апа турында сөйләгәндә, күңелләрне аларга карата тирән ихтирам, хөрмәт хисләре биләп ала. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Биккол авылында яшәүче Сәлим ага һәм Закира апа Сәгыйровлар гомер буена хөрмәтле гаилә булып саналдылар.**

Сәлим ага - сержант дәрәҗәсендәге солдат, Берлинны алуда һәм фашистлар Германиясен тар–мар итүдә катнашкан батырларның берсе. Ул - "Кызыл йолдыз" ордены, "Берлинны алган өчен" һәм башка бик күп медальләр белән бүләкләнгән сугыш ветераны. Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң, 1952 нче елда Закира апа белән матур гына гаилә корып җибәрәләр. Үзләре кебек игелекле, уңган, акыллы 6 бала тәрбияләп үстерәләр. Закира апа мәктәптә озак еллар буе балаларга белем һәм тәрбия бирә, аларны математика серләренә өйрәтә.Укучыларының уңышсызлыклары өчен чын күңелдән борчылып, кечкенә генә уңышларына да ихлас сөенә белгән мөгаллимә булды.

Ару-талуны белмәс тынгысыз җаннар пенсиягә чыккач та тик тормадылар. Сәлим аганың үзенең атын җигеп, янәшәсенә оныгын да сыендырып, болыннан печән чабып кайтулары, йорт тулы мал-туар, кош-корт асраулары, шул арада Закира апа белән җиләк- җимеш бакчасында мәш килеп оныкларына алма, кура җиләге җыюлары күз алдыннан китми. Ул да түгел, помидор, кыяр күтәреп кереп тирә-күршеләрен авыз итгерергә дә онытмыйлар. Нинди генә йомыш белән керсәң дә, беркайчан кире борып чыгармаслар алар.

Күпләр сокланырлык, көнләшерлек итеп яши белделәр. Һәрвакыт ярдәмчел, игелекле, мәрхәмәтле, юмарт булулары белән аерылып тордылар. Ә бит аларның да гаиләсендә төрле борчылулар, авырлыклар аз булмады, кайгы-хәсрәте дә читләтеп узмады. Гомер буе аларның нык ихтыярлы, көчле рухлы, сабыр холыклы булуларына сокланып яшәдек.

Сәлим ага белән Закира әби 63 ел бергә тату гына гомер итәләр. Ходай тәгалә аларны чыннан да пар канатлар итеп яраткан. Берсе – сугыш ветераны, икенчесе - ветеран укытучы. Дөрес, сәламәтлекләре какшау, олыгаю сәбәпле, бүгенге көндә Нурлатта кызлары Зәйнәп апа белән кияүләре Хәлим абыйның тәрбиясендә яшиләр.

Менә шундый авылдашларыбыз булганга сөенеп, үз укучыларыбызны да алар белән очрашуга алып бардык. Алар безне иң кадерле кунаклары кебек каршы алдылар. Күкрәге орден- медальләр белән тулы кечерәк буйлы Сәлим ага белән ап-ак яулыклы Закира әби һәм аларның кызлары, ачык йөзле Зәйнәп апа безнең килүебезгә бик шат иделәр. Сәлим ага һәм Закира әби укучыларга сугышның аяусызлыгын, Бөек Җиңүнең бик зур газаплар белән генә яулап алынуын һәм сугыштан соңгы чорның да бөтен авырлыкларын үз җилкәләрендә күтәрүләрен укучыларның күңеленә үтеп керерлек итеп тәфсилләп сөйләделәр. Укучылар аларны зур кызыксыну белән тыңлап утырдылар һәм үзләренең изге теләкләрен җиткерделәр.

**Рузилә СӘЙФУЛЛИНА, Әлфинә ГАЙФУЛЛИНА, Нурлат.**

